СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 31 августы Баулы шәһәре № 165

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы “Җирле үзидәрә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль Законга ярашлы рәвештә Баулы шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» Баулы муниципаль районы Советы карары проектын (1нче кушымта) хупларга һәм күмәк фикер алышуга чыгарырга.

2. 1нче кушымта нигезендә карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

3. Расларга:

- Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча күмәк фикер алышуда катнашулары тәртибен (2нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча күмәк фикер алышу үткәрү тәртибен (3нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы http//pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга:

- Баулы муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында” карары проектын (1нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча күмәк фикер алышуда катнашулары тәртибен (2нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча күмәк фикер алышу үткәрү тәртибен (3нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм тикшерү буенча эшче төркемне түбәндәге составта булдырырга:

1. Попов Сергей Александрович - эшче төркем рәисе.

2. Сафина Эльвира Әнис кызы - эшче төркем әгъзасы.

3. Багижева Светлана Николаевна - эшче төркем әгъзасы.

6. Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча күмәк фикер алышуны 2018 елның 21 сентябрендә сәгать 15тә түбәндәге адрес буенча Баулы муниципаль районы башкарама комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Баулы шәһәре, Куйбышев ур., 20.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы депутатларының һәм гражданнарның Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы муниципаль районы Советы тикшерүенә чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 31
августында кабул ителгән
165нче карарына 1нче
кушымта

Баулы муниципаль районы Советының
“Татарстан Республикасы “Баулы муниципаль районы”
муниципаль берәмлеге Уставын
кабул итү турында” карары
ПРОЕКТЫ

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131нче номерлы “Җирле үзидәрә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль Законга ярашлы рәвештә Баулы шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын яңа редакциядә кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турындагы карарны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен юстиция органына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы дәүләт теркәвенә куелганнан соң, аны кабул итү турында карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның
31 августында кабул
ителгән 165нче карарына
2нче кушымта

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча күмәк фикер алышуда катнашулары
ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 нче йорт адресы буенча Баулы муниципаль районы Советына язма рәвештә кертелә.

Тәкъдимнәр карар басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар шәхсән яисә почта аша түбәндәге адрес буенча бирелә: 423930, Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 (конвертта «Устав турында фикер алышу» яисә «күмәк фикер алышу» тамгасы белән).

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның
31 августында кабул
ителгән 165нче карарына
3нче кушымта

Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карары проекты буенча күмәк фикер алышу үткәрү
ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» карар проекты буенча күмәк фикер алышу (алга таба – күмәк фикер алышу) Татарстан Республикасының «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Күмәк фикер алышуда үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән шулай ук күмәк фикер алышу үткәрү комиссиясенә халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән район халкы да катнаша.

3. Күмәк фикер алышуда чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү фикер алышу башланганчы 1 сәгать кала башлана.

5. Күмәк фикер алышуда муниципаль берәмлек башлыгы яисә аның кушуы буенча муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты рәислек итә.

6. Күмәк фикер алышу рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, беркетмә төзү өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм секретариатның ике әгъзасы составында күмәк фикер алышу секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Күмәк фикер алышуда чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына карап чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Күмәк фикер алышуда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 3 минуттан да артык вакытка түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларының барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртип саклау фикер алышуда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Күмәк фикер алышуда  катнашучылар күмәк фикер алышу үткәрү тәртибен бозса, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче күмәк фикер алышу барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен ачык секретариат җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Күмәк фикер алышуда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма формада бирелә һәм күмәк фикер алышу беркетмәсенә теркәлә. Беркетмә рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм җирлек Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Күмәк фикер алышу нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Күмәк фикер алышуны уздыруны оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы Аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.